**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 1 июнь № 395

г. Казань

«2020 елга кадәр Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын үстерү» дәүләт программасының «2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын проектлау, төзү һәм перинаталь үзәкне эксплуатациягә кертү өлешендә модернизацияләү» ярдәмче программасын гамәлгә ашыру чаралары хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2011 – 2016 елларда Россия Федерациясе субъектларының сәламәтлек саклау системасын модернизацияләүнең төбәк программаларын Мәҗбүри медицина иминиятенең федераль фонды бюджетыннан бирелә торган акчалар исәбеннән финанслар белән тәэмин итү кагыйдәләрен раслау турында» 2011 ел, 15 февраль, 85 нче карары нигезендә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 елга кадәр Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 1 июль, 461 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 15 май, 319 нчы; 2014 ел, 10 декабрь, 966 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2020 елга кадәр Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын үстерү» дәүләт программасының «2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын проектлау, төзү һәм перинаталь үзәкне эксплуатациягә кертү өлешендә модернизацияләү» ярдәмче программасын гамәлгә ашыру максатында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән түбәндәгеләрне расларга:

«2020 елга кадәр Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын үстерү» дәүләт программасының «2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын проектлау, төзү һәм перинаталь үзәкне

эксплуатациягә кертү өлешендә модернизацияләү» ярдәмче программасы чараларын финанслар белән тәэмин итү кагыйдәләрен;

«2020 елга кадәр Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын үстерү» дәүләт программасының «2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын проектлау, төзү һәм перинаталь үзәкне эксплуатациягә кертү өлешендә модернизацияләү» ярдәмче программасын гамәлгә ашыру турында хисаплылыкны формалаштыру һәм тапшыру тәртибен.

2. Әлеге карар аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\395.doc

Татарстан Республикасы
Министлар Кабинетының
2015 ел, 1 июнь, 395 нче
карары белән расланды

**«2020 елга кадәр Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын үстерү» дәүләт программасының «2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын проектлау, төзү һәм перинаталь үзәкне эксплуатациягә кертү өлешендә модернизацияләү» ярдәмче программасы чараларын финанслар белән тәэмин итү**
**кагыйдәләре**

1. Әлеге кагыйдәләр «2020 елга кадәр Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын үстерү» дәүләт программасының «2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын проектлау, төзү һәм перинаталь үзәкне эксплуатациягә кертү өлешендә модернизацияләү» ярдәмче программасы (алга таба – Ярдәмче программа) чараларын финанслар белән тәэмин итү тәртибен билгелиләр.

2. Ярдәмче программа чараларын финанслар белән тәэмин итү Мәҗбүри медицина иминиятенең федераль фонды бюджетыннан Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды бюджетына бирелә торган субсидияләр һәм Татарстан Республикасы бюджет акчасы исәбеннән гамәлгә ашырыла.

3. Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды, Мәҗбүри медицина иминиятенең федераль фонды бюджетыннан субсидияләр күчерелгәннән соң биш эш көненнән соңга калмыйча, күрсәтелгән акчаларны башка бюджетара трансфертлар рәвешендә Татарстан Республикасы бюджетына Ярдәмче программа чараларын гамәлгә ашыруга юллый.

4. Башка бюджетара трансфертларны һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасын Ярдәмче программа чараларын гамәлгә ашыруга тоту Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан башкарыла.

5. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы түбәндәгеләрне тәэмин итә:

Ярдәмче программа чараларын гамәлгә ашыру максатында, яңа перинаталь үзәк төзүгә дәүләт заказы урнаштыруны һәм медицина җиһазы сатып алуны;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына яңа перинаталь үзәк төзүгә проект-смета документлары булу турында мәгълүмат, шулай ук сатып алуның якынча кыйммәтен күрсәтеп, медицина җиһазы исемлеген тапшыруны;

яңа перинаталь үзәкне проектлау, төзү һәм эксплуатациягә кертү барышын тикшерүдә тотуны.

6. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына яңа перинаталь үзәк төзүгә проект-смета

документлары булу турында мәгълүмат, шулай ук сатып алуның якынча кыйммәтен күрсәтеп, медицина җиһазы исемлеген тапшыра.

7. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына Ярдәмче программа чараларын гамәлгә ашыруга акча бирү Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан бюджет ассигнованиеләре күләмнәре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә тормышка ашырыла.

8. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, башка бюджетара трансфертлар счетка күчерелгәннән соң өч эш көне эчендә, финанслауның чик күләмнәрен Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына бюджет ассигнованиеләре күләмнәре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә җиткерә.

9. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, башка бюджетара трансфертлар һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы күчерелү турында мәгълүмат һәм Ярдәмче программа чараларын гамәлгә ашыруга максатында товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алуны тормышка ашыру нәтиҗәләре нигезендә, өч эш көне эчендә әлеге акчаларны Россия Федерациясенең дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр өлкәсендә контракт системасы турында законнарына ярашлы рәвештә дәүләт контракты төзегән оешмаларга күчерә.

10. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы яңа перинаталь үзәк төзүгә төзелеш кыйммәтенең һәм медицина җиһазы сатып алуның нигезлелеге өчен Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән тәртиптә җавап тота.

11. Ярдәмче программа чараларын гамәлгә ашыруга күчерелә торган акчаларны максатчан кулланмау законнар нигезендә җавап тотуга китерә.

12. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләнгән вәкаләтләр кысаларында Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының Ярдәмче программа чараларын гамәлгә ашыруга акчаларны тотуына, шул исәптән тикшерүләр һәм ревизияләр үткәрү юлы белән, контрольне тормышка ашыра.

______________________________________

Татарстан Республикасы
Министлар Кабинетының
2015 ел, 1 июнь, 395 нче
карары белән расланды

**«2020 елга кадәр Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын үстерү» дәүләт программасының «2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын проектлау, төзү һәм перинаталь үзәкне эксплуатациягә кертү өлешендә модернизацияләү» ярдәмче программасын гамәлгә ашыру турында хисаплылыкны формалаштыру һәм тапшыру тәртибе**

1. Әлеге Тәртип «2020 елга кадәр Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын үстерү» дәүләт программасының «2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын проектлау, төзү һәм перинаталь үзәкне эксплуатациягә кертү өлешендә модернизацияләү» ярдәмче программасын (алга таба – Ярдәмче программа) гамәлгә ашыру турында хисаплылыкны формалаштыру һәм тапшыру шартларын билгели.

2. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы ай саен, хисап аеннан соң килә торган айның 4 нче көненнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына, түбәндәге чыгымнарның шифрын ачып, хисаплар тапшыра:

Мәҗбүри медицина иминияте федераль фондының (алга таба – ММИФФ) «Россия Федерациясе субъектларының сәламәтлек саклау системасын модернизацияләүнең төбәк программаларын гамәлгә ашыру максатларына акча куллану турында хисаплылыкны тапшыру тәртибен һәм формасын билгеләү хакында» 2013 ел, 26 ноябрь, 237 нче боерыгы белән билгеләнгән тәртип һәм форма нигезендә, Россия Федерациясе субъектларының сәламәтлек саклау системасын модернизацияләүнең төбәк программаларын гамәлгә ашыруга ММИФФ бюджетыннан субсидияләр куллану турында;

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Россия Федерациясе субъектларының сәламәтлек саклау системасын модернизацияләүнең төбәк программаларын гамәлгә ашыру турында хисаплылыкны тапшыру тәртибен һәм формасын билгеләү хакында» 2013 ел, 20 декабрь, 965н боерыгы белән билгеләнгән тәртип һәм форма нигезендә, Ярдәмче программа чараларын тормышка ашыру барышы турында;

Татарстан Республикасында перинаталь үзәк төзүне һәм аны эксплуатациягә кертүне, Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтү буенча федераль хезмәт белән билгеләнгән тәртип һәм форма нигезендә, тикшерүдә тоту турында.

3. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы түбәндәгеләрне тапшыра:

ай саен, 5есенә кадәр, – Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органына Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтү буенча федераль хезмәт белән билгеләнгән тәртип һәм

форма нигезендә, Татарстан Республикасында перинаталь үзәк төзүне һәм аны эксплуатациягә кертүне тикшерүдә тоту турында хисап;

ай саен, 10ысына кадәр, – Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фондына, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан тапшырылган Ярдәмче программа чараларын гамәлгә ашыруга чыгымнарның шифрын ачып, ММИФФ белән билгеләнгән тәртип һәм форма нигезендә, Россия Федерациясе субъектларының сәламәтлек саклау системасын модернизацияләүнең төбәк программаларын гамәлгә ашыруга ММИФФ бюджетыннан субсидияләр куллану турында хисап;

квартал саен, 15енә кадәр, – Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы белән билгеләнгән тәртип һәм форма нигезендә, Ярдәмче программа чараларын тормышка ашыру барышы турында хисап.

4. Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды Мәҗбүри медицина иминияте федераль фондына ай саен, 15енә кадәр, ММИФФ белән билгеләнгән тәртип һәм форма нигезендә, Россия Федерациясе субъектларының сәламәтлек саклау системасын модернизацияләүнең төбәк программаларын гамәлгә ашыруга ММИФФ бюджетыннан субсидияләр куллану турында хисап тапшыруны тәэмин итә.

5. Ярдәмче программа белән күздә тотылган чараларны гамәлгә ашыру турында тапшырыла торган хисаплылыкның дөреслеге өчен җаваплылык Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләнә.